
# **Тема:** Талантлы якташларыбыз иҗаты.
# (9 нчы сыйныф укучылары өчен электив курс программасы).

**Укытучы:** Ибраһимова Рәмзия Касыйм кызы.
(югары квалификацион категорияле татар теле һәм әдәбияты укытучысы.)

Буа шәһәре 2 нче лицей, 2013 нче ел.

**Нәкыйме ул, Бакыймы ул-**
**бөтенесе билгеле.**
**Халкым юмарт!**
**Мондый ир-ат**
**һәрчак-кызыл**
**Р.**








Туган ил, туган авыл, туган як!


Һәр кеше өчен дә изге, кадерле сүзләр. Кеше үзенең туган ягын, аның тарихын, кешеләрен яхшы белсә генә милли җанлы, зыялы шәхес була ала.


Буа төбәге милләтебез өчен күп санлы талантлы шәхесләрне биргән як.





Буа төбәге









# Г. Гали-әдип, шәхес, гражданин



(1900-1954)

Журналист
“Безнең юл”
“Совет әдәбияты”


Беренче каләм тибрәтүе (1919-20нче еллар)

Язучы 15 ләп китабы дөнья
Күрә “Бәхет” “Кырда”, “Гайшә”...

Татарстан китап
Нәшриятын җитәкли
1927-1937

# Бакый Урманче






(1897-1990гг.)

**Сынлы сәнгатебезнең патриархы, аның башы аксакалы.**


**Н. Исәнбәт**







# Ринат Харис



1941

**Кешенең иң олы байлыгы-җир,**
**Җирнең иң олы байлыгы-Кеше.**

**Р.Харис**


Рус теле һәм әдәбияты укытучысы

Депутат Татарстан Дәүләт Советы Рәисе урынбасары

Шагыйрь.
«Ат иярләү»
“Кеше ораториясе”
“Җәлилчеләр”

Журналист
“Казан утлары”
“Яшь ленинчы”
“Татарстан яшьләре»

# Шариф Хөсәенов



Татарстанның атказанган табибы

Язучы
“Профессор кияве”
“Әни килде”
“Зөбәйдә-адәм баласы”

Опера арияләре пластинкалары җыя

Чәчәкләр үстерә (500ләп төрдә)










# "Театр яктылыкка илтә..."












Н. Төхфәтуллин
“Әйтер сүзем калдып эле”

Г. Айзатуллова
“Бәхет гөле”

# Бүгенге көндә иҗат итүче шагыйрьләр

Ф. Зыятдинова
Көмеш “Чулпы чыңы”

Р. Рахматуллин
Популяр – җырлар авторы

## Талантлы якташларыбыз иҗаты.

Нәкыйме ул, Бакыймы ул –
Халкым юмарт!
Мондый ир-ат
Һәрчак кызыл сөлгеле.

*Р. Әхмәтов.*

### Аңлатма язуы.

Туган ил, туган як, туган авыл! Һәр кеше өчен дә изге, кадерле сүзләр. Кеше үзенең туган ягын, аның тарихын, кешеләрен яхшы белсә генә милли җанлы, зыялы шәхес була ала.

**Буа төбәге** – милләтебез өчен күпсанлы талантлы шәхесләрне биргән як. Шушы якта туып-үскән танылган язучылар, шагыйрьләр, сәнгать
осталары – районыбызның олы горурлыгы. Яшь буынга шул турыда тулырак, тирәнрәк мәгълүмат бирү балаларның һәр яктан үсешкә ирешкән шәхес булып формалашуында зур роль уйный. Бу программа укучыларда милли үзаң формалаштыру, аларда әдәбият-сәнгатькә, туган төбәккә мәхәббәт, ихтирам хисләре тәрбияләүне күздә тотып төзелде.

**Программаның максатлары һәм бурычлары**

1. Яшь буынга Буа төбәгендә туып-үскән танылган язучылар, шагыйрьләр, галимнәр, сәнгать осталары турында тулырак мәгълүмат бирү;

2. укучыларга үткән тарихыбызны күзалларга ярдәм итү;

3. халкыбызның күренекле улларына карата ихтирам тәрбияләү, аларның иҗатлары аша укучыларда туган якка, табигатькә, әти-әниләргә мәхәббәт тәрбияләү һәм милли үзаң формалаштыру;

4. киләчәктә милләткә хезмәт итәрдәй яшьләр тәрбияләү.

**Курс ахырында укучылардан көтелгән нәтиҗәләр:**

1. Буа төбәгендә туып-үскән талантлы шәхесләрнең тормышын, иҗатын өйрәнү – балаларда туган яклары белән горурлану хисләре уята;

2. Курста өйрәнелгән темалар укучыларда милли үзаң формалаштыруга ярдәм итә. Йомгаклау дәресендә сайлап алынган темалар буенча рефератлар яклау – киләчәктә фәнни-тикшерү эшләре белән шөгыльләнергә этәргеч бирә.

3. Туган ягын, халкын, әниләрен яратучы, милләтебезгә тырышып хезмәт итүче яшьләр үсәр дигән өметтә калабыз.

Кереш  (Максат һәм бурычлар белән таныштыру).
1. **Г. Гали иҗаты**
Тормыш юлы һәм әдәбиятыбызда хезмәт җимешләре. Кеше тормышының һәм яшәүнең мәгънәсен аңлау - әдипнең төп максаты.
(Иске Тинчәле мәктәбенә экскурсия)

2. **Ш. Хөсәенов иҗаты.** (3 с.)
Язучы турында кыскача белешмә. Драматургия өлкәсендә эшчәнлеге. “Әни килде” әсәрендә сурәтләнгән ана образы, туганлык мөнәсәбәтләре.
(Өзекне сәхнәләштерү)

3. **Б. Урманчы иҗаты.** (2 с.)
Тәрҗемәи хәле һәм иҗаты. Иҗатында сурәтләнгән бөек шәхесләр, туган як табигате, хезмәт кешеләре.
4. **Р. Харис иҗаты.** (2 с.)
Тормыш юлы һәм иҗаты. Туган җир һәм туган як, аның табигатенә багышланган шигырьләре. Авыл кешеләре, аларның хезмәтен чагылдырга шигырьләре.
Милләт язмышы, бөек шәхесләр.

5**. Ф. Мортазин Р. Рәхмәтуллин иҗатлары (**1с.**)**
Биографияләре белән таныштыру. Татар җыр сәнгатен үстерү өлкәсендәге эшчәнлекләре. (Җырларын тыңлау)
6. **Буа шәһәрендә яшәп иҗат итүче шагыйрь – шагыйрәләребез.** (1с.)
Ф. Зыятдинова, Н. Төхфәтуллов, Г. Айзатуллова.
Туган җиргә, ата-анага булган изге хисләрен чагылдырган, мәхәббәткә дан җырлаган шигырьләре белән танышу. Алар белән очрашу.

7. **Буа театры.** (2 с.)
Буада бар бер театр. (Очрашу, спектакль карау һәм түгәрәк өстәл артында сөйләшү.)
8. "Үткәнең эзле, бүгенгең матур, киләчәгең якты булсын, Буам!" (1с.)
9. Якташларыбыз иҗатында Ана образы. (1с.)
10. Йомгаклау. Рефератлар яклау. (1с.)

| № | Эчтәлеге | Эш төрләре | Ярдәмлек матеиаллар, күрсәтмәләр | |
|---|---|---|---|---|
| Ринат Харис иҗаты (2 сәгать) (1941) | | | | |
| 1 | 1.Әдипнең тормыш юлы, иҗаты. | Терәк схемалар, лекция өлешчә эзләнү. | “Казан утлары” журналы, “Мәгариф” журналы, рәсем-иллюстрацияләр. | 1 |
| | Шагыйрь иҗатында күтәрелгән төп темалар | Туган як, Туган җир, аның табигате; хезмәт кешеләре турында шигырьләр уку. | Р. Харисның шигырьләр җыентыклары. | |
| 2 | Р. Харис – дәүләт эшлеклесе.<br>Милләт язмышы, бөек шәхесләр. | Очрашу. | | 1 |

## Бакый Урманче иҗаты. (2 сәгать)<br>(1897–1990)

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 3 | Тәрҗемәи хәле һәм иҗаты. | “Б. Урманче – сынлы сәнгатебезнең патриархы, аның башы, аксакалы” Н. Исәнбәт,<br><br>чыгышлар | Татар әдәбияты (10 кл.)<br>Вакытлы матбугат<br><br>материаллары | |
| | Олы иҗатчы мөрәҗәгать иткән<br><br>темалар. | Бөек шәхесләр<br>Туган як<br>Хезмәт кешеләре<br>турында рәсемнәр. | Б. Урманче күргәзмәсенә читтән торып экскурсия. | 1 |
| 4 | “Ул ташларны җырлата” | “Мин зур эшләр өчен туганмын”<br>Викторина“Рәсемне таны” | | |

| Шәриф Хөсәенов иҗаты (3 сәгать)<br>(1929-1999) | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 5 | Ш. Хөсәенов турында белешмә | Күренекле язучы, Татарстанның атказанган табибы. (лекция, өлешчә эзләнү) | Мавыгу: 500 ләп төрдәге кактуслар, опера арияләре пластинкалары, мәкальләр җыя. | 1 |
| 6 | Драматургия өлкәсендәге эшчәнлеге | "Професссор кияве", "Зөбәйдә-адәм баласы", "Әни килде" Фикер алышу, өзекләр уку. | | 1 |
| 7 | "Әни килде" драмасы | Әсәр 500 дән артык уйнала. | Өзекне сәхнәләштерү. | 1 |

| Г. Гали ижаты (2 сәгать)<br>(1900-1954) | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 8 | Г. Гали-әдип, шәхес һәм гражданин. | Буа районы Иске Тинчәле авылыннан чыккан күренекле язучы, публицист һәм тәнкыйтьче (лекция). | М. Мусин: “Г. Гали турында истәлекләр” | 1 |
| 9 | Әдәбиятыбызда хезмәт җимешләре | Беренче каләм тибрәтүе (1919-1920)<br>“Безнең юл”, “Совет әдәбияты”, “Отака” журналлары.<br>1927-1937 Татарстан китап нәшриятын җитәкли.<br>15 ләп китабы чыга. “Бәхет”, “Кырда” ...<br>Фикер алышу. | Иске Тинчәле мәктәбенә экскурсия | 1 |

# Ф. Мортазин, Р. Рәхмәтуллин иҗатлары
(1 сәгать)

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 10 | Биографияләре белән таныштыру | Татар җыр сәнгатен үстерү өлкәсендәге эшчәнлекләре фикер алышу, очрашу. | “Балалар өчен җырлар” китабы.<br>Җырларын тыңлау, өйрәнү.<br>Концертка бару. | 1 |
| **Буа шәһәрендә яшәп иҗат итүче шагыйрь-шагыйрәләребез.**<br>**(2 сәгать)** | | | | |
| 11 | Ф. Зыятдинованың тормышы.<br>Н. Төхфәтуллов | Шигырьләр җыентыгыннан сәнгатьле уку; | Яттан өйрәнү;<br>Газета чыгару “Әйтер сүзем калды әле” китабы. | 1 |
| 12 | Г. Айзатуллова. | Туган җиргә, ата-анага, мәхәббәткә дан җырлаган шигырьләре, очрашулар. | “Бәхет гөлем” китабы. | 1 |

# Буа драма театры (1 сәгать)

| | | | | |
|---|---|---|---|---|
| 13 | Буа театрының тарихы һәм бүгенгесе | Буада бар бер театр. (Театрга экскурсия, спектакль карау). | Түгәрәк өстәл артында сөйләшү. (Очрашуга Р. Садриевны чакыру) “Алсу томан”. | 1 |
| 14 | Якташ язучыларыбыз иҗатында Ана образы. | Укучыларның чыгышлары. | Шигырьләрдән, әсәрләрдән өзекләр | 1 |
| 15 | Үткәнең эзле, бүгенгең матур, Киләчәгең якты | Туган як музеена, Буа-аланга экскурсия | | 1 |